**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Яңа Тумба авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**18 июль 2019 ел** **№ 84**

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында**

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы эшен камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү буенча «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Тумба авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының законнарына һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмәне расларга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органына:

үз нормаларын чыгару эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;
әлеге Нигезләмә үтәлеше өчен җаваплы кешеләрне билгеләргә;
җаваплы итеп билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Нурлат муниципаль районының мәгълүмат сайтына урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге
Советы рәисе Л.Н. Осипов

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Яңа Тумба авыл җирлеге
Советының 2019 елның 18
июлендәге 84 номерлы карары
белән расланган

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының законнарга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы Нигезләмә**

**I. Гомуми нигезләмәләр**

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары законнарына һәм норматив хокукый актларына үзгәреш кертү мониторингы (алга таба – мониторинг, муниципаль актлар, җирле үзидарә органнары) җирле үзидарә органнары тарафыннан үз вәкаләтләре чикләрендә муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару), аларга үзгәрешләр кертү яки үз көчләрен югалткан дип тану (кире кагу) максатында мәгълүмат җыю, гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплексlы һәм планлы эшчәнлек алып баруны күздә тота.

2. Мониторинг җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә.

3. Җирле үзидарә органы мониторинг үткәргәндә Нурлат муниципаль районы Советы, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының юридик хезмәте (юридик бүлеге) белән хезмәттәшлек итә.

4. Җирле үзидарә органнарында мониторинг үткәрү өчен җаваплы затлар билгеләнә.

5. Мониторинг үткәрүнең максатлары булып:

федераль һәм республика законнарына туры китерү максатында муниципаль актларны кабул итү, аларга үзгәреш кертү яки үз көчләрен югалткан дип тану ихтыяҗлары барлыгын ачыклау;

муниципаль актларда коллизияләр, каршылыклар, бушлыкларны, хокукый җайга салуда кабатлауларны бетерү;

җирле үзидарә органнарының хокукый-норматив базасын системага китерүне тәэмин итү;

муниципаль актларда ришвәтчелек факторларын ачыклау;

гамәлдә файдаланылмаган (әһәмиятен югалткан) яки кулланылмый торган муниципаль актларны яки аларның аерым нигезләмәләрен (нормаларын) ачыклау;

хокук куллану нәтиҗәлелеген арттыру; муниципаль актларны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген киметә торган факторларны ачыклау;

җирле үзидарә органнарының тиешле бүлекчәләре тарафыннан муниципаль актлар үтәлешен тикшерүгә ярдәм күрсәтү;

нормалар чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

6. Мониторинг үзгәрешләрне җыю, гомумиләштерү, анализ һәм бәяләүне үз эченә ала:

федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка закон актлары;

Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актлары, федераль дәрәҗәдәге башка законга кагылышлы норматив хокукый актлар;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары;

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Тумба авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль актлары.

7. Мониторинг үткәрүнең нигезләре булып:

федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертү

хокукый җайга салу өлкәсендә муниципаль актларны куллануны анализлау;

прокуратура органнары мәгълүматы;

муниципаль актларны камилләштерү яки кимчелекләре турында массакүләм мәгълүмат чаралары мәгълүматы;

гражданнарның, юридик затларның, шул исәптән иҗтимагый, фәнни, хокук саклау һәм башка оешмаларның, шәхси эшкуарларның, дәүләт хакимияте органнарының, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларының муниципаль актларның камил булмавы турында мөрәҗәгатьләре, шул исәптән үз эченә түбәнлдәгеләрне алган мөрәҗәгатьләр:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелгән муниципаль актларга карата үткәрелгән хокукый экспертиза бәяләмәсе;

билгеләнгән тәртиптә вәкаләтле затлар тарафыннан әзерләнгән муниципаль актларга коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәләре;

җирле үзидарә органнары үткәрә торган конференцияләрнең, семинарларның, гаммәви тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышуларның һәм башка чараларның йомгаклау документлары керә.

## II. Мониторинг үткәрү тәртибе

8. Җирле үзидарә органнары әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән җаваплы затлар белән үзара бәйләнештә аларның компетенциясе мәсьәләләре буенча мониторинг үткәрәләр.

Мониторинг үткәрү максатларында эшче төркемнәр төзелергә, киңәшмәләр, консультацияләр үткәрелергә, кирәкле мәгълүмат соратып алырга, Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре, Россия Федерациясе субъектлары тәҗрибәсе өйрәнелергә, башка эш формалары кулланылырга мөмкин.

9. Мониторинг:

әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән актлар;

федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге норматив хокукый актларны дәгъвалау эшләре буенча суд актлары (суд практикасы) ;

прокурор актларын анализлау аша башкарыла.

10. Мониторингны гамәлгә ашыру, җирле үзидарә органнарының норматив базасын анализлау, шулай ук мониторинг йомгаклары буенча үткәрелгән нормалар иҗат итү эше нәтиҗәләрен фиксацияләү максатларында муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарында муниципаль норматив хокукый актлар реестрларын оештыру һәм алып бару тәртибе турында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары нигезендә башкарыла торган муниципаль норматив хокукый актлар реестрлары файдаланыла.

11. Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимизацияләү өчен мәгълүмат системаларының түбәндәгеләрне тәкъдим итүче автоматлаштырылган сервислары кулланыла (контрактлар, аларның операторлары белән килешүләр төзүгә бәйле күрсәтелгән мөмкинлекләр булганда):

«Гарант» мәгълүмат системасында закон һәм башка норматив хокукый актларга контрольгә куелган үзгәрешләр турында мәгълүмат керүне;

«Гарант» мәгълүмат системасын хокукый җайга салуның тиешле өлкәләре буенча яңалыклар тасмалары мәгълүматы керүне;

«Кодекс» мәгълүмат компаниясенең «Региональ законнар аналитигы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан муниципаль актларның законнарга туры килмәве турында мәгълүмат керүне.

Мониторингны гамәлгә ашыру процессын оптимальләштерү максатларында башка мәгълүмат системалары сервислары файдаланыла ала.

12. Муниципаль хокукый актларны кабул итүне (бастырып чыгаруны) тәэмин итү, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән анализ белән бергә үз көчләрен югалтуын (гамәлдән чыгаруны) тану өчен мониторингны гамәлгә ашырганда түбәндәге критерийлар буенча

муниципаль актларны куллану практикасы турында мәгълүмат гомумиләштерелә һәм бәяләнә:

кеше һәм гражданның гарантияләнгән хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;

муниципаль актларны кабул итү (бастырып чыгару) кирәклеген билгели торган югарырак юридик көчкә ия норматив хокукый актлар булу;

муниципаль акт кабул иткәндә җирле үзидарә органы вәкаләтләре чигендә эш итү;

муниципаль актта ришвәтчелек факторлары булу;

иҗтимагый мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуда тулылык;

хокук нормалары коллизиясе;

юридик-техник характердагы хаталар булу;

кулланган вакытта муниципаль акт нигезләмәләренең мәгънәсен бозу;

муниципаль хокукый актны кулланганда хокуксыз яисә нигезсез карарлар, гамәлләр (гамәл кылмау) булу;

норматив хокукый актларны куллану практикасы булу;

норматив хокукый актларны куллануның бертөрле практикасы булмау;

муниципаль актны аңлату мәсьәләләре буенча гаризалар булу (саны) һәм аларның эчтәлеге;

муниципаль акт белән җайга салынган мөнәсәбәтләргә бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүчеләрнең таләпләрен канәгатьләндерү (канәгатьләндерүдән баш тарту) турында законлы көченә кергән суд актлары һәм аларны кабул итү нигезләре булу (саны).

13. Мониторинг нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль актларны үзгәртүгә китерә торган федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр ачыкланган очракта:

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү, муниципаль актның үз көчен югалтуын тану, яңа муниципаль акт кабул итү турында муниципаль актларның тиешле проектлары эшләнә;

муниципаль актларны юридик көч актларына туры китерүгә юнәлдерелгән башка чаралар күрелә.

14. Муниципаль актларны үзгәртү ихтыяҗы тудыручы федераль һәм республика законнары актларына үзгәрешләр кертелгән очракта, федераль яки республика актын чыгарганнан соң 30 көн эчендә мониторинг үткәрелә.

Мониторинг үткәрүгә нигез булып гражданнардан, юридик затлардан, шәхси эшмәкәрләрдән, дәүләт хакимияте органнарыннан, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатларыннан кергән мөрәҗәгать, шулай ук прокуратура мәгълүматы торган очракта, «Россия Федерациясе прокуратурасы турында» Федераль законда билгеләнгән вакыт аралыгында карала торган прокурор актларыннан тыш, мониторинг мондый мөрәҗәгать һәм мәгълүмат кергән көннән соң 30 көн эчендә үткәрелә. Мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Федераль һәм республика законнары актларының ерак перспективада үз көченә керә торган үзгәрешләре ачыкланган очракта, җирле үзидарә органнарының норма чыгару эшчәнлеге планнарына тиешле төзәтмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертелә.

## III. Мониторинг нәтиҗәләрен тормышка ашыру

15. Муниципаль акт проектын эшләү һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча муниципаль акт кабул итү, әлеге нигезләмәнең 14 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, федераль һәм (яисә) республика законнарының тиешле акты үзгәртелгән көннән ике айдан да соңга калмыйча үткәрелә.

16. Лица, ответственные за проведение мониторинга, отчитываются перед руководителями органов местного самоуправления о результатах мониторинга не позднее 5 числа месяца, следующего за отчетным.

16.1. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат) үз эченә:

мониторинг үткәрү объекты турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрүнең башкаручылары турында мәгълүмат;

мониторинг үткәрү чоры турында мәгълүмат;

хокукый җайга салу предметының кыскача характеристикасын, мониторинг үткәрү нигезләрен алырга тиеш.

16.2. Мониторинг нәтиҗәләре турында хисап (мәгълүмат):

хокукый җайга салуның ачыкланган проблемалары турында мәгълүмат;

муниципаль актларга үзгәрешләр кертү һәм (яки) яңа муниципаль актларны кабул итү, юкка чыгару зарурлыгы турында тәкъдимнәр;

тиешле хокукый мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерүгә юнәлдерелгән мониторинг нәтиҗәләренә нигезләнгән башка нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәрне үз эченә сыйдырырга мөмкин.

17. Мониторинг нәтиҗәләре буенча яңа кабул ителгән муниципаль актлар законда каралган тәртиптә һәм вакыт аралыгында Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрелә.

Әлеге регистрга кертү өчен элек анда кертелгән актлар түгел, мониторинг нәтиҗәләре буенча ачыкланган муниципаль актлар җибәрелә.

18. Мониторинг нәтиҗәләре буенча норма чыгару процессын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләнергә мөмкин.

## IV. Җаваплылык

19. Мониторинг үткәрү һәм хокукый иҗат итү эшчәнлеге өчен җаваплы затлар мониторингны оештыру, шулай ук муниципаль актларны җирле үзидарә органнары карамагына караган тиешле хокукый җайга салу өлкәсендә федераль һәм республика законнарына туры китерү өчен шәхси (шул исәптән дисциплинар) затлар җаваплы.

20. Тискәре нәтиҗәләргә, шул исәптән гражданнарга, юридик затларга, җәмгыятькә һәм дәүләткә зыян китергән мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлләр (гамәл кылмау) өчен законнар нигезендә җирле үзидарә органнары җитәкчеләре җаваплы.